Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән мәктәп олимпиадасы биремнәре
2017-2018 уку елы
5 нче сыйныф

Үткәрү вакыты – 60 минут.
Максималь балл – 36

I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Алфавит тәртибендә бирелгән сүзләр рәтен билгеләгез. ***(2 балл)***

а) нарат, тузан, туфрак, тун
ә) бака, бавыр, балалар, бозлавык
б) ишек, йокы, яфрак, элгеч
в) җиләк, җим, өстәл, урындык

2. Калын сузык авазлардан гына торган сүзләр рәтен билгеләгез. ***(2 балл)***

а) куян, сыер, елан, болан
ә) кәҗә, төлке, тиен, бүре
б) тамыр, кушымча, нигез, сүзлек
в) читлек, каен, батыр, төтен

3. Ясалма сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) өчпочмак, даруханә, сандугач, чәк-чәк
ә) тәмле җиләк, яшел урман, танылган җырчы, тирән чокыр
б) юлбарыс, хатын-кыз, авылдаш, дәү әни
в) утыра, ашый, көлә, җырлый

4. Бәйлекләрдән генә торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) кебек, өчен, белән, кадәр
ә) һич, кенә, үк, иң
б) -ны/-не, -ның/-нең, -лы/-ле, -даш/-дәш
в) ник? кайда? кем? нишли?

5. Сыйфатның кимлек дәрәҗәсен ясый торган чаралар дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) бик, дөм, үтә, җете
ә) -су, -сыл/-сел, -гылт/-гелт, -кылт/-келт, -ылҗым/-елҗем
б) -рак/-рәк
в) зәп-, сап-, кып-, ап-.

6. Билгеле киләчәк заман хикәя фигыль кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Гүзәл әнисенә савыт-саба юарга булышты.

ә) Әминәне күргәч, әбисе шатланыр.

б) Якшәмбе көнне Әнәс бакчага күп итеп агачлар утыртачак.

в) Тәрбияле бала һәрвакыт өлкәннәргә ярдәм итә.

7. Рәвеш сүз төркемнәре генә кулланылган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) матур, акыллы, сабыр, җәйге

ә) быел, тиз, юри, русча

б) көз, шимбә, һава, яңгыр

в) кызгана, ачуланды, шатланыр, санаган

8. Кушма җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Көзге каникулда Айзилә Казанга сәяхәткә барачак.

ә) Айгөл, Ләйсән һәм Булат бакчадагы коелган яфракларны җыялар.

б) Концертта укучылар биилләр, җырлыйлар, шигырь сөйлиләр.

в) Көз җитте, һәм кошлар җылы якларга киттеләр.

II. Теоретик бирем.

Боерык фигыль турында белгәннәрегезне языгыз. ***(10 балл)***

III. Иҗади бирем.

Т хәрефеннән башланган сүзләрдән генә торган 5 җөмлә языгыз. Алар үзара мәгънә ягыннан бәйләнгән булсыннар. ***(10 балл)***